| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___09.03.2023___ Казан ш. № __54_______

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 сентябрендәге 111 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 09 сентябрендәге 111 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2016 елның 12 февралендәге 19 номерлы, 2018 елның 24 гыйнварындагы 7 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне

кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Нигезләмәгә, шулай ук Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) боерыкларына таянып эш итә.»

7 пунктта:

«а» пунктчасында «Дәүләт комитетының бухгалтерлык хисабы һәм дәүләт заказы бүлеге дәүләт хезмәткәрләре» сүзләрен «Дәүләт комитетының финанс, дәүләт заказы һәм мобилизация эше бүлеге дәүләт хезмәткәрләре» сүзләре белән алмаштырырга;

«б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Дәүләт комитеты рәисе Комиссия составына «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә Дәүләт комитеты каршында төзелгән Иҗтимагый совет вәкилен кертү турында карар кабул итә ала;

9 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов